**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә шәһәр тибындагы бистәсе №20 25 сентябрь 2017 ел

Актүбә шәһәр тибындагы бистә биләмәсендә үзара салым җыю һәм куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре" турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның уртак принциплары" турындагы 131 номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән "Җирле референдум" турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Актүбә шәһәр тибындагы бистә Уставының 12 маддәсе, Актүбә шәһәр тибындагы бистә башкарма комитетының 2017 елның 18 сентябрендә чыккан 27 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары, Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының 18 сентябрь 2017 елда чыккан 18 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары нигезләрендә,

Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы карар кабул итте:

1. Актүбә шәһәр тибындагы бистә биләмәсендә үзара салым җыю һәм куллану буенча 2017 елның 19 ноябрендә референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   "Сез, Актүбә шәһәр тибындагы бистә биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2018 елда 300 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме. Үзара салым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Үзара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   1) янгын сүндерү гидрантлары алу һәм урнаштыру;
   2) каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар алу;
   3) урам яктылыгы өчен өстәмә яктырткычлар алу һәм аларны монтажлау;
   4) яңа мөселман һәм христиан зиратларын төзекләндерү (контейнерлар кую өчен мәйданчыклар төзү, шул исәптән контейнерлар алу, су өчен савытлар алу һәм аларны урнаштыру, зиратка илтүче юлларны, туктау урыннарын төзекләндерү, квартал эчендәге юлларны төзекләндерү, яңа христиан зиратында җиһазлар кую өчен будка һәм ритуаль хезмәтләр башкару өчен бина төзү) өчен.

"ӘЙЕ" "ЮК".

3. Әлеге карар районның “Маяк” газетасында бастырылырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталының http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырылырга, Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырылырга тиеш.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис: Р.А. Галеева